**ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021ел 8 ноябрь

№ 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авылы җирлегендә Петровка авылы гражданнарның 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Петровка авылы, Пушкин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча 2021 елның 18 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслрга: «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлеге Петровка авылында теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Петровка т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру);
2)Пушкин урамы буенча Петровка т. п. буенча шлагбаум урнаштырӳ(материаллар сатып алу);
3) некрологларны район «Сарман» газетасында бастыру.;

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация

челтәрендә, Кәүҗияк авылы территорясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов